СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево, 422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы, 422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.05.2019 — с. Большие Меми — 56-253

**Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Башлыгы Г.А.Фоминаның мәгълүматын тыңлаганнан соң, Олы Меми авыл җирлеге Советы тарафыннан хупланган «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнгән, җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерелгән һәм җирлек халкы белән фикер алышу өчен кирәкле барлык процедуралар да үткәрелгән, дип билгеләп үтә. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставының 19, 88-90 статьялары нигезендә,

**Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставына № 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен расларга.

3. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Олы Меми авыл җирлеге Башлыгы** **Г.А.Фомина**

Олы Меми авыл җирлеге
Советының 27.05.2019 елгы
56-253 карарына
1 нче кушымта

**Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1.2. Олы Меми авыл җирлеге Уставының 6 статьясының 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән мөрәҗәгать итү буенча эшчәнлек алып бару».

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Олы Меми авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Г.А.Фомина**